РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» март 2022 ел г. Альметьевск № 419

Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүче аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында». 2018 елның 25 июнендәге 864 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хокукый мониторинг кысаларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә эшләүче аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 864 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 декабрендәге 1827 номерлы, 2022 елның 28 гыйнварындагы 99 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым учреждениеләрнең айлык тариф ставкалары күләмнәре Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган Әлмәт муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә.»;

5 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) айлык тариф ставкасының 8 проценты күләмендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр;».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов